«Адымнар-Түбән Кама» күптелле гимназиясе

# АдымнарTimes

Полилингвальная гимназия «Адымнар-Нижнекамск»

№ 3, декабрь 2023 г.

adymnartubenkama
adymnartubenkama



*Татарстан Республикасының атказанган артисты Эльмира Калимуллина «Адымнар» гимназиясендә кунакта, 4 нче бит*

## АНОНС

7 **Ближе к искусству:** *мастер-класс для педагогов в стиле модерн*

7 **Пушкинский бал:** *назад в прошлое*

8 **Из Калининграда с любовью:** *об «Адымнар» узнали в Восточной Пруссии*

**ТАТАРЧА ЯЗАБЫЗ**

2 **«Адымнар»га беренче адым:** *беренче сыйныф укучылары өчен зур бәйрәм*

3 **«Сәләт Биләр Форум»:** *адымлылар сәләттә*

5 **Эльмира Калимуллина:** *бәхеткә юл кайдан башлана?*

5 **КВН:** *«Әйдә, киттек «Адымнар»га!»*

**ENGLISH**

6 **Our school's mission:** *«Nurturing greatness»*

6 **Simple English with native speaker**

6 **An adventurous summer with CLIL**




**Яркий фотоальбом** 8 стр.



## Слово редактора



### УВАЖАЕМЫЕ ЧИТАТЕЛИ!

**Рады презентовать вашему вниманию третий номер нашей газеты!**

В нём мы сделали акцент на материалах, связанных с эстетическим воспитанием детей.

Встреча ребят с заслуженной артисткой РТ Эльмирой Калимуллиной, Пушкинский бал, фестиваль Дружбы народов, мастер-класс для педагогов в стиле модерн, КВН.

Газетада һәркем күңеленә хуш килгән язма, үзе өчен кызыклы булган мәгълүмат табар дип ышанабыз.

Рәхәтләнеп укыгыз!

*Ихтирам белән,*
*газета мөхәррире*
*Ксения ПУШКАРЁВА*

## Рәсми

# «АДЫМНАР»ГА БЕРЕНЧЕ АДЫМ!

**Балаларны мәктәпкә озату – һәрбер ата-ана өчен дә дулкынландыргыч һәм мөһим вакыйга, чөнки алар тормышларының яңа бер этабына аяк басалар.**

**Белем дөньясына 1 нче сыйныф укучылары тәүге адымнарын ясадылар. Хәзер алар үзләрен мәктәп гаиләсенең чын әгъзалары дип атый ала.**



24 нче октябрьдә «Беренче сыйныф укучыларына багышлау» тантанасы узды. Бу чара укытучылар һәм укучылар тарафыннан бергәләп әзерләнде. Әлеге кичәне рус һәм татар телләрендә үткәрү бик отышлы. Нәни укучыларыбыз өчен бәйрәм – ул уен. Баланың психикасын формалаштыруына, аның шәхес буларак үсешенә, аның хисләренә һәм эмоцияләренә тәэсир итә. Бәйрәм бала тормышында аерым урын алып тора. Сәхнәдә шигырьләр сөйләп, алар үзләренең гади генә балалар булмауларын, ә чын укучылар булуларын расладылар. Нәкъ менә мәктәп бәйрәмен әзерләү һәм үткәрү вакытында укучының фантазиясе киңәя, сәләте үсә. Шул рәвештә инициативалы, эзләнүчән шәхес формалаштыру өчен нигез барлыкка килә. Иң нәтиҗәлесе – танып белү эшчәнлеге үсеше. Бу максаттан югары сыйныф укучылары да тантананы әзерләүдә актив катнашты. Аларга төп роль бирелде. Үзара хезмәттәшлек нәтиҗәнең мөһим шарты булып тора. Бергә эшләү, бер төркемдә булу, һичшиксез, зарури. Бәйрәмгә әзерлек барышында беренче параллель укытучылары белән рухи-әхлакый һәм эстетик сыйфатларны тәрбияләүгә юнәлдерелгән зур эш башкарылды: бәйрәм сценарием эшкәртү; актлар залын бизәү; җырлар, бию, шигырьләр сайлау һәм өйрәнү; музыкаль озата бару; номерлар сайлап алу. Болар барысы да – мәктәп укучыларын һәм укытучыларын берләштерергә ярдәм итте, мәҗбүрилек һәм җаваплылык сыйфатларын үстерүгә этәргеч булды.

Балаларга мәктәпкә кагылышлы сүзләрне аера белү уены бик тә ошады. Гадәттәгечә, бәйрәм ахырында ант бирелде. Балалар яхшы укырга, мәктәп кагыйдәләрен үтәргә вәгъдә иттеләр. Шул биргән антларына һәр бала гимназияне тәмамлап чыкканчы, тугры булып калыр дип ышанабыз.

1 нче сыйныф укучыларын котлыйбыз! Аларны алда озын да, кызыклы да, авыр да, мавыктыргыч та, күңелле дә юл көтә! Ул юлның якты мизгелләргә һәм яңа җиңүләргә бай булуын телибез!

*Мәсүфә Гыймранова,*
*уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары.*

*Гөлназ Сергеева,*
*Эльмира Гобәйдуллина,*
*Айгөл Мостафина,*
*башлангыч сыйныф укытучылары*

## Семинар

# Республикакүләм семинар-практикум

**25 нче октябрендә Яр Чаллы шәһәренең 59 нчы «Адымнар-Чаллы» күп телле гимназиясендә «Федераль белем бирү программаларын гамәлгә кертү шартларында туган телне һәм әдәбиятны укыту» темасына республикакүләм семинар-практикум үтте.**

Әлеге чарада Казан, Әлмәт, Алабуга, Түбән Кама шәһәрләренең «Адымнар» мәктәбе директорлары, директор урынбасарлары һәм татар теле һәм әдәбияты укытучылары, Яр Чаллы шәһәренең барлык мәктәпләреннән милли белем һәм тәрбия бирү буенча директор урынбасарлары катнашты. Бер җөмлә белән әйткәндә, татар теле укытучылары тәҗрибә уртаклашты.



Бу нисбәттән, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф бүлеге җитәкчесе Энҗе Гыйззәтуллина бер кызыклы хикәят тә сөйләп алды. Ике урман кисүче ярыша-ярыша эшли икән. Берсе туктап та тормый, ди. Икенчесе бераз эшли дә, туктап ала икән. Болай булгач, мин җиңәм, дип уйлаган туктамаганы. Әмма, ни гаҗәп – туктый-туктый эшләгәне моны узып та киткән икән. «Ничек шулай булды әле бу?» дип гаҗәпләнгән беренче урман кисүче. Ә көндәше: «Мин берничә тапкыр балтамны үткенләдем», – дип җавап биргән. «Безгә дә эш арасында тәҗрибә уртаклашып, яңа белемнәр туплар өчен вакыт табарга кирәк», – дип нәтиҗә ясады Энҗе ханым.

Семинарны 59 нчы «Адымнар-Чаллы» күп телле гимназиясенең директоры Азат Галиев чыгышы һәм укытучылар коллективы «Кунак» биюе белән ачып җибәрде. Аннары кунаклар ике төркемгә бүленеп дәресләр, мастер-класслар, чыгышлар карадылар.

Семинар «Килер гасырларның аръягына Илең белән бергә уз, Тукай» дигән темага Габдулла Тукайга багышланган әдәби-музыкаль кичә белән «Туган тел» җырын җырлап тәмамланды. Бу чара бик нәтиҗәле һәм мавыктыргыч булды. Укытучылар үзләренә бик күп кызыклы мәгълүматләр җыйдылар.

*Гөлназ Сабитова,*
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

**ФОРУМ**

# СӘЛӘТ МОХИТЕ – АКЫЛ, РУХ ҺӘМ ТЕЛ БЕРЛЕГЕ!

**23-27 июнь көннәрендә Сәләтле Адымлылар беренче сменага – ҺӨНӘРЛӘР БИЛӘР ФОРУМГА җыелган иде!**

Биләр Форум – гаҗәеп мохитле уникаль урын! Ул – Республикабызның төрле почмакларыннан килгән катнашучыларның танышу һәм дуслашу урыны. Бу масштаблы сменада Сәләт берләшмәсе, Адымнар Клубы лидерлары һәм безнең «Адымнар - Түбән Кама» активистлары да бар иде. Ул ел саен «Изге чишмә» мемориаль комплексында, ягъни «Хуҗалар тавы»нда оештырыла. Биредә балалар салкынга бирешмичә, ата-бабаларыбызның тирән рухы булган җирдән үзләренә энергия җыя, изге чишмә суларыннан көч ала, Хуҗалар тавына менеп, канатлана! Сәләт Биләр Форум – ул аралашу, танышу, дуслар һәм 24 сәгать саф һава.

Бу форум Адымлыларның киләчәктә үз-үзләрен үстерүләренә һәм яңа һөнәрләр өйрәнүләренә багышланган иде. Анда төрле уен һәм мотивацияне арттыручы дәресләр, остаханәләр узды, сәлкешләребез төрле белем өлкәләрен үзләштерде. Нейротехнологияләр; «Робоняша» робототехникасы (Роботлар ясау һәм аларны JavaScript телендә программалаштыру); молекуляр биология; планерлар җыю; рәсем сәнгате, каллиграфия, химия; камил IT-продукт, шәм, кәгазь, барельеф ясау; эксперименталь фән, фешн-иллюстрациядә татар дизайны һәм бердвотчинг – төп темалары булды.

Безнең мәктәптән 81 бала (1-7 нче сыйныфлар) катнашты. Алар арасында: фән олимпиадалары, конференцияләр һәм иҗади фестивальләрнең җиңүчеләре һәм призерлары, югары уку нәтиҗәләре буенча сайлап алынган балалар. Әлеге сменада укучыларыбыз үзләрен төрле өлкәләрдә сынап карадылар.

Адымлыларыбыз төрле хан исемнәрен йөрткән аланнарга бүленгән иде. Мәсәлән, Кодрак Хан, Күлтәгин, Модә, Алмас Хан, Илкам Хан, Атилла һ.б. Һәрбер аланның үзенә хас сөрәне бар иде. Сәлкешләребез аны өйрәнеп, һәр чара башлану алдыннан кабатладылар.




Сменаның һәр көне уку-укыту программасы, уеннар, спорт ярышлары һәм кечке чаралар белән үрелеп барды. Смена вакытында укучылар волейбол, шахмат, бура һәм бочче чемпионатларында, интеллектуаль турнирларда (ЧГК), джем-сессияләрдә, тотрыклы үсеш максатлары буенча уеннарда һәм башка күп кенә активлыкларда катнаша алдылар. «Бер, ике, өч, дүрт – Биләр супергуд!» интерактив кичәсе һәм һәр сәлкешнең зарыгып көтеп алынган чараларның берсе – дискәтүк – беркемне дә битараф калдырмады. Адымлылар рәхәтләнеп биеде! Гомумән, Адымлыларыбыз көн дә күңелләренә хуш килгән дәресләргә йөрде.

Сәләттәге радио – ул аерым тема. Көн дәвамында Форум территориясенә махсус радио хәбәрләр ирештерелде. Җыр-моңнар һәрберсен сөендерде! Балалар 7:30 - 20:00 аралыгында Selet FM радиосын тыңлады! «Хәерле иртә», «Хәерле көн», Сәләт гимны, «Ашарга, барабыз ашарга...», «Мин-Сәләт һәм бу җәен...», «Мин инде әзер, ә син әзерме...», «Ач күзләреңне - очарга вакыт җитте...», «Тыныч йокы...», Азнакай, Саба, Рухият һ.б. аланнарның танылып, таралган җырлары күңелләрдә мәңге истә калыр... Монда телисеңме, теләмисеңме, татар телен тыңлап кына да өйрәнә аласың.

Татар теле дигәндә, Сәләтнең бер низамәте болай яңгырый: «СӘЛӘТ мохитендә Инглиз теле – ИПИ, рус теле – СУ, ТАТАР теле – ҺАВА». Иписез без 1-2 атна тора алабыз, сусыз 1-2 көн, ә һавасыз 1-2 минут. Татар теле безгә ҺАВА кебек кирәк. Сменаларда катнашу өчен татар телен камил белү мәҗбүри булмаса да, бу форумнарда татар телле мохит тудырыла, тәрбия бирелә, мәдәни чаралар туган телебездә үткәрелә.

Укытучылар өчен (безнең Адымнар мәктәбеннән алар 15 кеше иде) әйдәп баручы белгечләрдән махсус «Остаз» проекты булдырылды. Проект кысаларында әхлакый кыйммәтләр, мәктәпләр белән идарә итү һәм баланың шәхесен үстерү темаларына багышланган сессияләр һәм остаханәләр узды.

Өстәмә буларак, «Адымнар» делегациясе «Сәләт» проекты җитәкчесе Җәүдәт Сөләйманов белән очрашты. Түгәрәк өстәл кысаларында катнашучылар ике оешманың эшчәнлеге турында фикер алышты. Ә «Адымнар» мәктәпләрендә «Сәләт сыйныфы» проекты җитәкчесе Айнур Җамалетдинов еллар узган саен «Сәләт» белән «Адымнар»ның хезмәттәшлеге ныгый баруы турында сөйләде.

Форумда «Җанлы Сәләт» турыдан-туры эфирлар студиясе эшләде. Трансляцияләрдә «Сәләт» яшьләр үзәге директоры Айгөл Габдрахманова һәм безнең «Адымнар-Түбән Кама» полилингваль гимназиясе директоры Артур Галиәхмәтов катнашты. «Җанлы Сәләт» ярдәмендә һәр теләгән кеше, өеннән чыкмыйча да, форумның онытылмаслык мохитенә кушыла, Биләр җирендә барган вакыйгаларны күзәтә ала. Трансляцияләр форумның ВКонтакте һәм YouTube официаль челтәрләрендә алып барылды.

*Зөлфия Ашрапова,*
*инглиз теле укытучысы,*
*«Сәләт – Адымнар Түбән Кама»*
*клубының җитәкчесе*



ЭКСКЛЮЗИВНО

# Эльмира Калимуллина: «ТОРМЫШКА АШМАГАН ХЫЯЛЛАР – МИНЕМ ӨЧЕН

**Гимназиябезнең яшь журналистлары Татарстан Республикасының атказанган артисты, «Голос» проектының финалисты Эльмира Калимуллина белән интервью үткәрделәр.**

**Очрашу кысаларында катнашучылар кунагыбыз һәм гимназиябезнең татар һәм төрек телләре укытучысы Эльвина Айрат кызы Унверен башкаруында «Өмет йолдызы» җырын тыңлап үттеләр. Бу үзе бер мәртәбә!**

**Онытылмас чарабыз имза кую һәм истәлеккә фотосурәткә төшү белән тәмамланды.**



**Динияр Шарифуллин: Гаиләгезнең тарихы турында нәрсә беләсез? Нәселегездә нинди һөнәр ияләре бар?**

**Эльмира Калимуллина (Э.К.):** Бик яхшы сорау! Минем карт әбием – Ольга Арсентьева, Урал якларында кулак малын тарату заманында карт бабаем Лотфуллага кияүгә чыга. Аның нәселендә таш һәм агач осталары, хәзрәтләр һәм укытучылар булган. Әти ягыннан әбием 11 нче мәктәптә укытучы булып озак еллар дәвамында хезмәт итте. Хәзерге вакытта әнием уку үзәгендә эш итә. Абыем исә – техника фәннәре кандитаты. Үзем хәзерге вакытта музыка укытучысы булып эшлим.

**Амелия Массарова: Поделитесь, пожалуйста, яркими моментами вашего детства.**

**Э.К.:** Для меня детство – это то, что связано с бабушкой и дедушкой с маминой стороны. Они были очень строгие, но так нас любили! Помню, как дэу эника учила меня чистить свежую картошку, мыть липовой мочалкой полы в бане. Перед глазами картина, как мы собирали березовые веточки для веников, выкапывали картошку: сначала с одного участка в 16 соток, потом с другого в 9 соток.

**Сәмирә Ялалова: Сез ничә яшьтә җырлый башладыгыз? Әлеге теләк ничек барлыкка килде?**

**Э.К.:** Беренче тапкыр 6 яшемдә сәхнәгә чыктым. Әлеге теләк табигый рәвештә барлыкка килде. Балачактан ук музыка мәктәбенә йөри идем. Гаиләм һәрвакыт минем иң зур терәгем булды.

**Рузалия Мухамеджанова: Вам было страшно выступать впервые на сцене?**

**Э.К.:** Мне было 6 лет, и я так кайфанула! У меня было красивое платье, сандалики, бант. На сцене – моя любимая Алия апа. А сколько цветов подарили! Наверное, не было критического мышления, и я просто не знала, что нужно бояться.

**Анастасия Романова: Каким образом родители поддерживали в желании стать певицей?**

**Э.К.:** У них не было цели, чтобы я стала певицей, но они видели, что мне очень нравится музыка. Помню, маме часто говорили: «Зачем ты покупаешь концертный костюм – купи стиральную машину!» Но это была её интуитивная инвестиция в моё будущее *(улыбается)*. Родители всегда верили в меня, просто были рядом.

**Виктория Голякова: Как Вы попали на проект «Голос» и с кем из знаменитостей познакомились?**

**Э.К.:** Подала заявку по интернету. Меня пригласили на прослушивание, начались телевизионные этапы. Я оказалась в команде Пелагеи. Познакомилась со всеми наставниками: Димой Биланом, Александром Градским и Леонидом Агутиным. Взаимодействовала с группами «Моральный кодекс», «Чайф» и другими

**Аделина Моисеева: Әлеге проектта остаз сыйфатында катнашыр идегезме?**

**Э.К.:** Юк, Аллам сакласын. Ул бик катлаулы эш. Әлегә мин моңа әзер түгел.

**Азалия Кәримова: Сез әлеге проектта катнашып, үзегез өчен нинди мөмкинлекләр ачтыгыз?**

**Э.К.:** Беренчедән, масштаб. Икенчедән, шушы проект ярдәмендә мин сезнең белән таныштым. Өченчедән, тәҗрибә тупладым. Мин үз-үземне таптым. Хәзер үземә ышанам. Чикләремне ашам. Көн саен үземә нинди дә булса яңалык ачам. Мин «Голос» проектына бик рәхмәтле!

**Диләрә Вакилова: Сезнең өчен татар телендә язылган иң кадерле җыр кайсысы? Ул нәрсә турында?**

**Э.К.:** Әлбәттә, минем иҗатымда иң мөһим җыр – «Өмет йолдызы» *(Эльмир Низамов көе, Ренат Харис сүзләре)*. Ул «Зөләйха күзләрен ача» фильмында яңгырады, шуңа күрә күп кешегә таныш. Бу җыр минем өчен бик үзенчәлекле. Ни өчен? Чөнки бу җыр тыңлаучыларымның яшь чиген киңәйтте, күп кенә кешенең күңелен кузгатты.

**Камилла Ганиева: Есть ли у Вас какие-то ритуалы перед выступлением?**

**Э.К.:** Да. Мне нужно остаться хотя бы на 2 минуты одной, чтобы меня никто не беспокоил. Сконцентрироваться, прочесть молитву. Важный ритуал – собраться с музыкантами и участниками балета вместе, сцепиться руками, пожелать удачи и… так мы выходим на сцену.

**Булат Нуруллин: Есть ли другие профессиональные области, которые Вас привлекают?**

**Э.К.:** Я очень люблю танцевать. Возможно, занялась бы художественной гимнастикой. Еще интересна психология, вокальное искусство как педагогика.

**Илиза Галимова: Вы снимались в фильме «Золотая Орда». Какой опыт получили?**

**Э.К.:** Просто колоссальный! Первый день – самый стрессовый: я хотела собрать вещи и уехать. Я же думала, что всё получится с первого дубля! Самой сложной стала сцена, в которой плачу. Нужно было максимально сосредоточиться на состоянии, а рядом со мной рассказывают анекдоты, настраивают свет, шумят… Научилась работать с эмоциями, правильно выстраивать коммуникацию: когда грамотно разговариваешь с гримерами, тебе наложат самый классный грим; если нашёл подход к оператору, он будет любить тебя в кадре, выставляя нужный свет. Вообще кино – это мощная индустрия, где всё очень точно: из-за минуты опоздания, может «полететь» вся смена, а это 12 часов!

**Амина Халиуллина: Расскажите, пожалуйста, в каких странах хотели бы побывать?**

**Э.К.:** В Австралии. Муж настоль-

# ЗУР БӘХЕТ!»





ко эмоционально описывал эту страну, что мне захотелось там побывать. А если говорить о городах, посетила бы Мурманск – мечтаю увидеть северное сияние!

**Ларина Иванова: У меня вопрос о школе: какие предметы Вам нравились, а какие тяжело давались?**

**Э.К.:** Мне очень нравилось ИЗО – был интересный педагог, который разрешал нам фантазировать, любила литературу. Тяжело давалась геометрия, была сложной математика, хотелось понимать физику, но, увы! *(смеется)*.

**Алия Срурова: Поделитесь, пожалуйста, впечатлениями о нашей школе.**

**Э.К.:** Я скажу так: у нас, по сравнению с вашими условиями, была Спарта. У вас всё есть! Тренажерный зал, бассейн, а в этой шикарной библиотеке можно дневать и ночевать! Ребята, у вас прекрасная школа! Мы о такой только мечтали!

**Эльвина Гыйльманова: Буш вакытыгызны ничек уткәрәсез?**

**Э.К.:** Йоклыйм. Әлегә буш вакытым юк. Савыт-саба юам, улымның уенчыкларын җыям, массажга йөрим.

**Ләйлә Садыкова: Сезнең өчен иң мәгънәле бүләк кайсысы?**

**Э.К.:** Мин бәхетле кеше. Мин – әни, хатын, кыз, сеңел. Иҗатка килгәндә, якын дустым Эльмир Низамов белән галиҗанәп тандемыбыз гөрләп эшли. Ә иң олы һәдия – ул мине яратып, миңа ышанып яшәүче кешеләр. Авырлык китергәннәргә дә аеруча рәхмәтлемен.

**Салих Латыпов: Что для Вас было самым сложным на пути к славе?**

**Э.К.:** Отличный вопрос! Знаете, у каждого своё понимание славы. Вообще не очень люблю это слово – «слава», давайте будем говорить «известность». Говорят, самое важное – быть самим собой, и это же является самым сложным. Построить правильный диалог с внутренним «я», понять свои истинные желания и научиться не конфликтовать с ними. Именно тогда открывается тот путь, который нужен. Не бойтесь смотреть трогательные фильмы и читать непростые книги – это вас наполняет! Если вас обижают – получайте удовольствие! Это ваш эмоциональный багаж. Будьте внимательны к знакам мира – всё не просто так.

**Айзилә Хәсәншина: Сезнең чынга ашырмаган хыялыгыз бармы?**

**Э.К.:** Бу сорауга фәлсәфи яктан җавап бирер идем. Хыяллар бардыр, мөгаен. Әмма бу хыяллар чынга ашмаган икән, димәк, Аллаһы Тәгалә шулай юлымны күрсәткән дип уйлыйм. Бәлки, тормышка ашмаган хыяллар – минем өчен зур бәхеттер. Минем карт әбием гел әйтә иде: «Тели белсәң – теләк, тели белмәсәң – имгәк». Хәерлесен генә сора дип һәрвакыт кисәтә иде.

ЮМОР

# «ӘЙДӘ, КИТТЕК АДЫМНАРГА!»

10 нчы ноябрь көнне безнең яраткан гимназиябездә Татарстан Республикасының «Адымнар» полилингваль комплексларының һәм гимназияләренең Әлмәт, Чаллы, Алабуга, Түбән Кама һәм Актаныш командалары арасында «Әйдә, киттек Адымнарга!» дип аталган беренче татар КВН фестивале узды. Әлеге уенда республикадагы барлык «Адымнар»дан 5 команда катнашты.

Командаларның чыгышларын хөрмәтле жюри әгъзалары – «Татарстан Республикасы тарих һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды» коммерциягә булмаган оешманың башкарма директоры Сөнгатуллина Зөлфия Хафиз кызы, Түбән Кама мәгариф идарәсе методисты Исмәгыйлова Резеда Раиф кызы, 37 нче лицей директоры Котляр Динара Дамир кызы, XIII «Сәләт» клубының президенты Мөхәммәтҗанов Данис Зөлфәт улы, шәһәр КВН клубының активисты Алена Пушкарева бәяләделәр. Җиңүчеләр грамота һәм сертификатлар белән бүләкләнделәр. Зөлфия Хафиз кызы «Яңарыш» фонды исеменнән барлык катнашучы командаларга Болгар шәһәренә юллама бүләк итте.

Һәр биремгә әзерлек, киемнәр, шаян биюләр әзерләү, атрибутика сайлау, сценарий язу, артистизм укучылардан да, педагог-оештыручылардан да зур көч, тапталмаган яңа фикерләр һәм зур җаваплылык сорады. Гимназия тормышыннан көлкеле хәлләрне, җыр-биюләрне үз эченә алган сәламләү, өй эше, СТЭМ биремнәренә әзерлектә һәр сүзгә, һәр хәрәкәткә күп мәгънә салынды. Җор теллелек, тапкырлык, шаянлык мимик хәрәкәтләрдә дә чагылыш тапты.

Нәтиҗәләр түбәндәгеләр: 1 нче урын «КараМай» (Әлмәт); 2 нче урын «Мандарин» (Актаныш); 3 нче урын «Каймак» (Түбән Кама). «Сәләт – Адымнар Түбән Кама» клубының рәисе Моисеева Аделина «Чын татар кызы» булып танылды.

КВН уены укучыларыбызда нинди хис-кичерешләр уятты икән:

**Сафина Нуриева, 8 нче Б сыйныфы укучысы:** *«Без дусларыбыз белән татарча КВНда бик теләп катнаштык. Әзерлек барышында без бер-беребезгә тагын да якынайдык, дуслаштык. Сәхнәдә чыгыш ясау, уйнау миңа бик ошады. Безне әзерләгән укытучыларга, гимназиябез директоры Артур Кәрим улына зур рәхмәт әйтәсем килә!»*

**Аделина Моисеева, 6 нчы Б сыйныфы укучысы:** *«Миңа калса, КВНда уйнаучы өчен төп максат – тукталып калмау, чөнки хәрәкәт – ул тормыш, үсеш. Киләчәктә «Адымнар» КВН кубогы бездә булыр диген теләктә калам».*

**Илина Фәзуллина, 7 нче Г сыйныфы укучысы:** *«Безнең командада бар яктан да уңган, оста, шаян егетләр һәм кызлар көч сынаштылар. Кыска гына вакыт эчендә гимназиябез тормышын чагылдырган кызыклы чыгышлар әзерләргә өлгердек. Безне әзерләгән, ярдәм иткән, яраткан татар теле укытучыларыбызга зур рәхмәт!»*

**Радмир Габиев, 7 нче А сыйныфы укучысы:** *«Беренче уен миндә уңай хис-кичерешләр уятты, хәтта бераз гаҗәпләндерде дә. Ә бит, чыннан да, кызык! Ә иң мөһиме: татарча! КВНда уйнагыз, аны карагыз, КВНны яратыгыз, дуслар. Яшәсен КВН!»*

Адымлыларны җиңүләре белән котлыйбыз һәм киләчәктә дә уңышлар теләп калабыз! Афәрин! Барлык оештыручыларга һәм катнашучыларга гимназиябез данын яклаган өчен зур рәхмәтебезне белдерәбез! Киләчәктә дә зур үрләр яуларга насыйп булсын!

***Энже Зайдуллина,***
***туган тел һәм әдәбият укытучысы***



FROM THE WORLD OF ENGLISH

# EFFECTIVE TECHNIQUES AND METHODS IN LANGUAGE LEARNING

The Big Teachers' Week is the key event of the Year of Teacher and Mentor. On the 3rd of October, 2023, our gymnasium hosted a regional seminar for teachers of foreign languages «Effective techniques in language learning in multilingual environment».

More than 80 teachers from Nizhnekamsk and other towns in Tatarstan and Bashkortastan participated in the seminar. The event was held with the participation of the Head of the Department of National Education of the Ministry of Education and Science of the Tatarstan Republic Ilgiz Khalikov and the Head of the Department of Education of Nizhnekamsk district - Aidar Garifullin.

The teachers of the gymnasium presented modern creative methods of teaching foreign languages, such as: English, Turkish, Chinese and Arabic. The guests of the seminar visited the integrated CLIL lessons of geography and technology. In the second part of the seminar, participants took part in a master class from the winners of the Algarysh grant. Emil Saifullin, Aigul Bikmukhametova and Evgeniya Hatipova spoke about content and language integrated learning (CLIL). CLIL objectives are varied, for example, 'To improve students' proficiency in both their mother tongue and the target language, To develop the intercultural understanding, social and thinking skills'. The main aim of CLIL is to improve the educational system.

The seminar had a positive feedback from the participants. They were impressed by school facilities, motivated students and creative teachers. Our aim is to hold this event annually in October.

***Regina Abdieva, Guzel Mingalieva, teachers of English***

Traditions

# VALUES AS A CORNERSTONE OF SUCCESSFUL EDUCATION




Our school's mission «Nurturing greatness», is realized through different aspects of education. One of them is value-based education. VBE is unique in the sense that the curriculum focuses on ethical and emotional intelligence and values, which gives students the best chance of personal happiness and well-being, as well as academic success. By creating a solid learning environment, it enhances academic performances and develops personal and interpersonal skills that persist after graduation and throughout life.

Every month of the school year is focused on some specific value. In September, our school community practised Purposefulness, October – Diligence, November – Friendship. The purpose of a value-based curriculum is to help the school community reflect on the values that are important to them. This opens up discussion and encourages personal responsibility. Every Tuesday, we have Assembly where students talk about values, express their personal views and make connections with their own lives. This helps students develop their understanding of values in relation to themselves, the world and human experience. During the month, students take part in activities with teachers and parents where they practice skills of communication, research and perform themselves through the perspective of the value.

At the end of each month, the Class of the month is chosen, which gives confidence and sense of success to each student.

***Gulnaz Sadrieva, Deputy Principal of «Adymnar-Nizhnekamsk»***

# AN ADVENTUROUS SUMMER WITH CLIL

**Last summer four of our teachers spent two weeks studying, practicing English and travelling in Turkey. Arthur Galiakhmetov, Aigul Bikmukhametova, Evgenia Hatipova and Emil Saifullin won the republic's scholarship program «Algarysh». They took a course related to content and language integrated learning (CLIL) at the International Training Institute in Istanbul, Turkey.**

The teachers attended classes to get acquainted with CLIL approach in teaching. This approach involves learning subjects such as history, geography, biology, maths and others, through an additional language. It can be very successful in enhancing the learning of languages and other subjects, and helping children develop a positive attitude towards themselves as language learners. CLIL focuses on preparing students for the globalized world. It helps to increase students' motivation to learn foreign languages and develop intercultural competence.

Thanks to the schedule, our teachers had time not only study but also visit some famous sights in Istanbul and Turkey. They even managed to visit Cappadocia, a historical region in Central Anatolia. This trip was one of the most unforgettable events, they saw a lot of historical places and had an amazing view of hot-air ballooning.

Our teachers returned from the trip full of new knowledge, ideas and techniques which they use in teaching process.

**Emil Saifullin, Aigul Bikmukhametova, teachers of English**



## SIMPLE ENGLISH WITH NATIVE SPEAKER:

# FIRST STEPS TO THE HEIGHTS OF KNOWLEDGE

**This year, speaking courses with a native speaker were opened in Adymnar. They are led by a teacher from Nigeria, Mr. Rodney Obulor. «It is best to start learning a foreign language with Natives», this is the conclusion our high school students came to. That's what they say about it.**

**Arina Semenova, 8 grade:** «So, it's like you're being thrown into the center of a lake and you're forced to swim. In lessons with Mr. Rodney, I began to speak English almost immediately and very actively. There's significant progress with each new lesson, I add to my vocabularies, I understand better how to speak, and how not to, etc».

**Maksim Burov, 8 grade:** «We just communicate with Mr. Rodney on abstract topics. He quickly solves my pronunciation problems and effectively teaches me how to speak English».

**Ayaz Khasanov, 8 grade:** «Mr. Rodney explains the grammar rules better and more clearly, he always corrects us if we make mistakes or say something wrong. My listening comprehension has improved significantly, my pronunciation has improved, and my knowledge of spoken English has deepened».

**Samira Fatkhullina, 8 grade:** «I started studying with Mr. Rodney not so long ago (about a month), but I am very happy! Classes are held in a relaxed atmosphere, easy and very informative. Rodney patiently explains the material and is not surprised by funny questions; I really hope that our classes will last for a long time».

**Safina Nuriyeva, 8 grade:** «I really like classes with Rodney, especially that the lesson is built for the student so that he is comfortable, and we are able to catch up on forgotten moments in the language and, most importantly, the balance of grammar and speaking is maintained, there is enough time for everything».

СОХРАНЯЯ ТРАДИЦИИ

# Пушкинский бал

**«Балы, красавицы, лакеи, юнкера. И вальсы Шуберта, и хруст французской булки…» Именно так и не иначе хочется начать разговор о первом в истории гимназии Пушкинском бале.**

Девушки – в пышных платьях, юноши – в строгих фраках с бабочками. Под легкую музыку в непринужденной атмосфере ведутся светские беседы…

«Посмотрите-ка, а ведущие-то что ни на есть – сам Александр Пушкин с супругой-красавицей Натальей Гончаровой!» – слышим шепот в толпе. «А третий, третий-то кто? Никак Николай Васильевич Гоголь! Точно он!»

Игра в фанты, музыкальный «Ручеёк», стихи, романсы, польки и мазурки – что может быть веселее и романтичнее?



Однако одними забавами торжество не ограничилось. На сцене были показаны настоящие театрализованные постановки! Вот хитрый Сальери подсыпает яд наивному Моцарту («Моцарт и Сальери», 8Б), Пугачев стращает юного Петра Гринёва («Капитанская дочка», 8А), а жена графа пытается прекратить давний спор мужа с Сильвио, перерастающий в настоящую стрельбу («Выстрел», 8В).

Ярким моментом бала стала песня «Комета» («Буря мглою небо кроет») в исполнении педагога Эльвины Айратовны Унверен. Ребята с восторгом слушали нетрадиционную подачу стихов Пушкина в современной интерпретации.

Ну, а завершился бал, конечно же, вальсом и яркой фотосессией на память!







Мастер-класс

# «Су Анасы в стиле Густава Климта»

**Мастер-класс по живописи под таким названием был проведен в День учителя для педагогов гимназии.**

Идейными вдохновителями и организаторами мероприятия стали учитель изобразительного искусства Ильнара Исламовна Мухаметгалиева и учитель русского языка и литературы Ксения Сергеевна Пушкарева.

Художественное направление модерн было выбрано неслучайно: растительные элементы и орнамент – изюминка картины. Центральное место в работе занимает образ Су Анасы - мифического существа из фольклора тюркских народов.

На протяжении 3 часов педагоги работали над будущими шедеврами акрилом и поталью. Прослушали интересную лекцию по истории модерна и узнали факты биографии австрийского художника Густава Климта. Одним из участников стал мистер Родни – приглашенный преподаватель английского языка. Кстати, гость выучил несколько фраз на татарском языке!

Завершилось мероприятие фотосессией и чаепитием в уютной обстановке.



**Успехи**

# ЗОЛОТО И СЕРЕБРО – НАШЕ!



Коллектив гимназии стал обладателем почетного 2 места в номинации «Хоровое исполнительство» конкурса «Творческая панорама-2023». Педагоги исполнили две песни: патриотическую «Гүзәл җирем» и собственный гимн на трех языках «Мы – «Адымнар», учителя». Последняя является кавер-версией известной песни «We're the Champions» группы Queen. Специально для конкурса педагоги гимназии переработали её под нашу стилистику: на татарском языке – Эльвина Унверен, на русском языке – Светлана Грачева, Ксения Пушкарева, Лилия Булатова, Марина Халиуллина. По итогам общественного мнения «Мы – «Адымнар», учителя» стала одной из топовых песен и негласным гимном гимназии.

Также специальной номинацией «Солист хора» был отмечен директор «Адымнар-Нижнекамск» Артур Каримович Галиахметов.

Кроме того, обладательницей первого места в номинации «Сольное пение» стала учитель татарского и турецкого языков Эльвина Айратовна Унверен с песней «Өмет йолдызы».

Поздравляем коллег с прекрасными результатами! Так держать!

**Акция**

# ТАТАРЧА ДИКТАНТ

**Татарча диктант акциясенең асылы – Россия Федерациясе һәм дөньяның төрле шәһәрләрендә барлык теләгән кешеләр өчен ихтыяри һәм бушлай уздырыла торган диктант. Акциядә һәр кеше катнаша алды.**

31 илнең 5 меңнән артык мәйданчыгында туган телләрен яратучы, үз белемнәрен тикшереп карарга теләүче 1 100 000 якын милләтәшләребез җыелды.

Быел татарча диктант сигезенче тапкыр уза. Дөньякүләм «Татарча диктант»



акциясендә «Адымнар – Түбән Кама» мәйданчыгында 70 укучы катнашты. Диктантны язганнан соң, тиз арада нәтиҗәләр шәхси кабинетка кертелде, алар 15 ноябрьдән соң diktant.tatar сайтында билгеле булды.

**Алина Исмәгыйлова, директор урынбасары**

# «Адымнар Times» – в Калининграде!

Редактор газеты «Адымнар Times» Ксения Пушкарева в ходе путешествия по Калининградской области (бывшая территория Восточной Пруссии) посетила музей «Старая немецкая школа Вальдвинкель». В качестве презента директору музея Инессе Наталич было вручено два номера газеты «Адымнар Times».




**Новинки**

# Арт-объекты с пользой





В рамках проекта «Занимательная переменка» гимназистам презентовали напольные шахматы. Оригинальное игровое поле разместилось в фойе второго этажа. Едва появившись, шахматы стали культурной достопримечательностью и вызвали небывалый интерес у адымнаровцев. Мы искренне надеемся, что игра значительно повысит интерес к этому виду спорта и разовьёт умственные способности наших учеников.

Кроме того, интересным новшеством стали баскетбольные мини-площадки, установленные на этажах гимназии. Играя, дети кидают мусор в кольцо, пролетая через которое он оказывается в корзине. Вот так креативно мы наводим порядок!

# «Адымнар-FEST»



*Башлангыч сыйныфлар арасында Гран-прига 3 Б сыйныфы лаек булды. Балалар Һиндстанны тәкъдим иттеләр.*



*Өлкән сыйныфлар арасында чегән халкын тәкъдим иткән 8 В сыйныфы иң яхшысы дип танылды.*

Редактор – К.С.Пушкарева.
Корректор – М.В.Халиуллина.
Помощь в переводе и литературная правка на татарском языке – Э.А.Унверен.
Помощь в подборе контента – З.М.Ашрапова.
Консультанты – А.А.Исмагилова, Г.И.Садриева, М.Р.Набиева, М.М. Гимранова.
Редакция газеты благодарит за помощь всех педагогов и детей, принявших участие в выпуске газеты.

В газете размещены фото, сделанные педагогами и сотрудниками школы, а также взятые из открытых источников.
МБОУ «Адымнар-Нижнекамск», пр. Строителей, 66А.
423570, РТ, г. Нижнекамск
Телефон: 8 (8555)35-05-35.
E-Mail: adymnar.tk@inbox.ru

Отпечатано в ООО «ИПЦ «Гузель» г. Нижнекамск, пр. Химиков, д. 18, тел.: 8 (8555) 49-80-04
Заказ № 38227/22
Тираж 100 экз.
Декабрь, 2023 г.
Вёрстка и дизайн – И.И. Шалафаев

Мы в Telegram: adymnartubenkama
Мы в «ВКонтакте»: adymnartubenkama